**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Башкарма комитеты**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАРЫ

2020 елның 22 мае 7№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына салым чыгымнары Исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 21 маендагы 6 номерлы «2020 елда Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибен раслау турында» карары белән расланган салым чыгымнары исемлеген төзү һәм Татарстан Республикасы Иске Камка авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү Тәртибенең 6 пункты нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына салым чыгымнары Исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда һәм Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Камка авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Ф.А.Акберов

Расланган
Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлегенең
Башкарма комитетының
2020 елның 22 маендагы
7 номерлы карары

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына салым чыгымнары Исемлеге**

| Ташламаны, азат итүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акт | Норматив хокукый актларда билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Салым ташламаларын, азат ителүне һәм башка преференцияләрне билгели торган НХА нигезләмәләренең үз көченә керү даталары | Салым ташламаларына, азат итүгә һәм башка преференцияләргә хокук бирелгән НХА гамәлдә булу датасы | Салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Салым ташламаларының, азат итүләрнең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булуын туктату датасы | Салым ташламаларының, азат итүләрнең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең атамасы | Салым чыгымнарының максатчан категориясе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 ноябрендәге 30 номерлы "Физик затлар милкенә салым турында"гы карары | Түбәндәге салым салу объектларына карата: 1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә; 2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше; 3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында күрсәтелгән бина | 1.18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган салым түләүчеләр; 2. 1 пунктта күрсәтелгән салым түләүчеләрнең балалары . | 01.01.2019 | 01.01.2019 | Чикләнмәгән (ташламаның гамәлдә булуы туктатылган көнгә кадәр) | Билгеләнмәгән | Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү. Ташлама салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүченең эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмаган салым салу | Социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яисә корылма; 4) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык бинасы яисә корылма; 5) гараж яисә машина урыны | | | | | | объектына карата салым түләүче тарафыннан тиешле салым суммасы күләмендә бирелә. | |
| Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 ноябрендәге 30 номерлы "Физик затлар милкенә салым турында"гы карары | Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирларга карата. | Фатир хуҗалары | 01.01.2019 | 01.01.2019 | Чикләнмәгән (ташламаның гамәлдә булуы туктатылган көнгә кадәр) | Билгеләнмәгән | Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү. Ташлама әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясеннән салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнгән суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә бирелә. Фатир гомуми милектә булган очракта, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә | Социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | исәпләнә. | |
| Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 маендагы 12 номерлы "Җир салымы турында"гы карары. | Түбәндәге категориядәге затларга карата:<br>1) Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары;<br>2) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;<br>3) «Чернобыль АЭС һәлакәте аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында»(1992 елның 18 июнендәге 3061-I номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә) Россия Федерациясе Законы, 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы «1957 елда «Маяк» житештеру берләшмәсендә булган авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны | Җир кишәрлекләре милекчеләре | 01.01.2018 ел | 01.01.2018 ел | Чикләнмәгән (ташламаның гамәлдә булуы туктатылган көнгә кадәр) | Билгеләнмәгән | Җир салымын түләүдән азат итү. | Социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» Федераль закон һәм 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган физик затлар;<br>4) шәхси ярдәмче хуҗалык өлешендә территориядә эшләүче янгыннан ирекле саклау әгъзалары. | | | | | | | |
| ӘМР Иске Камка авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 ноябрендәге 24 номерлы «2018 елның 31 маендагы «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль | Сәнәгать билгеләнешендәге җир кишәрлекләрендә инвестицион бизнес-проектларны гамәлгә ашыручы инвесторларга карата» | Инвестицион бизнес-проектларны гамәлгә ашыручы инвесторлар | 01.01.2020 ел | 01.01.2020 ел | Чикләнмәгән (ташламаның гамәлдә булуы туктатылган көнгә кадәр) | Билгеләнмәгән | Җир салымын түләүдән азат итү. | Социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| берәмлеге Советының «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары. | | | | | | | | |